**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕКАБАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

Кәньяк урамы, 1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

---

**2025 елның«16» октябре** **8 номер**

# БОЕРЫК

**Кадастр номеры 16:24:160303:3931 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 39 статьялары, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 18 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы, Территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының мөрәҗәгате, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең "Кадастр номеры 16:24:160303:3931 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында"2025 елның 13 октябрендәге 8588/исх номерлы хаты нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге, Олы Кабан авылы, Георгий Давыдов урамы, 18 нче йорт, «кибетләр»адресы буенча урнашкан 16:24:160303:3931 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. үткәрү датасы һәм вакыты – 2025 елның 14 ноябрендә 15.00 сәгатьтә;

2.2. Уздыру урыны - Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Олы Кабан авылы, Җиңү ур., 5 й.

2.3. Гавами тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне язма рәвештә түбәндәге адрес буенча җибәрергә: ТР Лаеш районы Кече Кабан авылы, Көньяк ур., 1 й.

2.4. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты 2025 елның 13 ноябренә кадәр.

3. Әлеге карарны «Камская новь» район газетасында, интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Олы Кабан**
**авыл җирлеге башлыгы урынбасары А.И. Маков**